Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

17 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 109 номерлы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1.Черемыш авылында 2021 елның 1 декабрендә 14.00 сәгатьтә Гурин урамындагы иске чиркәү янында халык җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2022 елда Черемыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2.Олы Бутырка авылында ике этапта гражданнар җыены үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 1 декабрендә 14.00 сәгатьтә Осипов урамындагы кибет янында (12А йорт) үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Киров урамы буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2 декабрендә 16.00 сәгатьтә Осипов урамындагы кибет янында (12А йорт) үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Осипов, Тукай урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2022 елда Олы Бутырка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге А.Р. Сәйфетдинов